# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«20» 02 2019 ел  №313

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 6 сентябрендәге 4049 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 30 декабрендәге 1278 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 6 сентябрендәге 4049 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тукай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә:

III бүлекнең 3 пункты 3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Өлкән тәрбиячеләргә, тәрбиячеләргә, музыка буенча җитәкчеләргә, укытучы-дефектологларга, укытучы-логопедларга, педагог-психологларга, кече тәрбиячеләргә, турыдан-туры мәктәпкәчә яшьтәге укучылар (тәрбияләнүчеләр) белән эшләүче тәрбияче ярдәмчеләренә:

гомуми үсеш юнәлешендәге төркемнәрдә (төрле яшьтәге төркемнәрне дә кертеп):

ике айдан өч яшькә кадәр - 15 бала;

өч яшьтән белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр - 20 бала;

гаилә белеме формасындагы төркемнәрдә - 7 бала;

компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәрдә өч яшькә кадәрге һәм аннан өлкәнрәк балалар өчен:

сөйләмнәрендә зур тайпылышлар булган балалар өчен - 6 бала һәм 10 бала;

сөйләмнәрендә фонетик-фонематик тайпылышлар балалар булган өчен - 12 бала;

саңгырау балалар өчен - яшь ягыннан ике төркем өчен 6 бала;

начар ишетүче балалар өчен - 6 бала һәм 8 бала;

сукыр балалар өчен - яшь ягыннан ике төркем өчен 6 бала;

начар күрүче балалар, амблиопия, кылый күзлелек белән авыручы балалар өчен - 6 бала һәм 10 бала;

терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен - 6 бала һәм 8 бала;

психик үсеше тоткарланган балалар өчен, җиңел дәрәҗәдә акыл ягыннан артта калган балалар өчен - 6 бала һәм 10 бала;

уртача, авыр дәрәҗәдә акыл ягыннан артта калган өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен - 8 бала;

аутистик спектр тайпылышлары булган балалар өчен - яшь ягыннан ике төркем өчен 5 бала;

катлаулы дефектлары булган (физик һәм (яки) психик үсештә ике яки аннан да күбрәк кимчелек булган) балалар өчен - яшь ягыннан ике төркем өчен 5 бала;

катнаш юнәлештәге төркемнәрдә:

өч яшькә кадәр - 10 баладан да артык түгел, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән 3 баладан артык түгел;

өч яшьтән өлкәнрәк:

10 баладан артык түгел, шул исәптән 3 саңгырау яки сукыр баладан, яки терәк-хәрәкәт аппараты бозылган баладан, яки уртача, авыр дәрәҗәдә акыл ягыннан артта калган баладан, яки аутистик спектр тайпылышлары булган баладан, яки катлаулы дефектлары булган баладан артык түгел;

15 баладан артык түгел, шул исәптән 4 начар күрүче һәм (яки) амблиопия һәм (яки) кылый күзлелек белән авыручы баладан, яки начар ишетүче баладан, яки сөйләмендә авыр тайпылышлар булган баладан, яки акыл ягыннан артта калган баладан;

17 баладан артык түгел, шул исәптән психик үсеше тоткарланган 5 баладан артык түгел;

сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәрдә өч яшькә кадәрге һәм аннан өлкәнрәк балалар өчен:

туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен - 10 бала һәм 15 бала;

еш авыручы балалар һәм махсус сәламәтләндерү чаралары комплексы кирәк булган башка категория балалар өчен - 10 бала һәм 15 бала.»;

3.2 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарны 3 эш көне дәвамында районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов